**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 24 маендагы ПУ-196 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты актларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 8 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 6 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 6 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты указлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларының үз көчен югалткан нигезләмәләре исемлегенең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәгә

үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 10 декабрендәге ПУ-1186 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 10 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 20 май
№ 328

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «20» маендагы
328 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе (алга таба шулай ук – Идарә) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

Идарә Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына. Идарә эшчәнлегенә үзенең вазыйфаи бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе күзәтчелек итә.

2. Идарә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт протоколы практикасының төп нигезләмәләрендә билгеләнгән чаралар һәм нормалар белән Татарстан Республикасы дәүләт протоколын гамәлгә ашыру максатларында төзелде.

3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Татарстан Республикасының чит ил партнерлары белән эшен Идарә халыкара практикада гомумкулланыштагы беркетмә нормаларын, Дипломатик багланышлар турындагы Вена конвенциясе нигезләмәләрен, тышкы эшчәнлектә катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрнең характерын, Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында барлыкка килгән беркетмә практикасы нормаларын исәпкә алып төзи.

4. Идарә турында нигезләмәне Татарстан Республикасы Рәисе раслый.

## II. Идарәнең төп бурычлары

5. Идарәнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы Рәисенең халыкара элемтәләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисенең чит илләргә визитларын һәм чит ил делегацияләренең Татарстан Республикасына визитлары кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе катнашындагы чараларны беркетмә-оештыру ягыннан тәэмин итү;

Татарстан Республикасына чит ил делегацияләренең, чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмалар вәкилләренең иң югары һәм югары дәрәҗәдәге визитларын беркетмә-оештыру ягыннан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисенең Россия Федерациясе субъектларына визитларын һәм Татарстан Республикасы буйлап сәфәрләрен беркетмә-оештыру ягыннан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе катнашында уздырылучы башка чараларны беркетмәгә нигезләү ягыннан тәэмин итү һәм аларны оештыруда катнашу;

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Рәисе катнашында рәсми чаралар уздырганда бердәм беркетмә практикасын тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы Премьер-министрының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең халыкара визитларын беркетмәгә нигезләү ягыннан тәэмин итүдә катнашу.

## III. Идарәнең төп функцияләре

6. Идарәнең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы дәүләт беркетмә практикасын камилләштерү;

Татарстан Республикасына чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар вәкилләре, Россия Федерациясе субъектлары һәм федераль дәүләт органнары җитәкчеләре визитлары барышында тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасы Рәисе катнашындагы чаралар программаларын әзерләү, әлеге программаларны үтәү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар белән хезмәттәшлек итү;

Татарстан Республикасы Рәисенең чит илләргә һәм Россия Федерациясе субъектларына визитлары, Татарстан Республикасы буенча сәфәрләре программаларын әзерләү, әлеге программаларны үтәү буенча үзара эшчәнлекне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты белән берлектә Татарстан Республикасы Премьер-министрының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең рәсми халыкара визитларын, шулай ук Татарстан

Республикасына килүче югары дәрәҗәдәге чит ил делегацияләрен мәгълүмат-аналитик һәм беркетмәгә нигезләү ягыннан тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасында иң югары һәм югары дәрәҗәдәге делегацияләрне кабул иткәндә әзерлек төркемнәре эшен тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт беркетмәсе нигезләмәләре буенча кунакларны кабул итүгә әзерлек һәм аларның яшәү шартларын тәэмин итү чаралары комплексын уздыру;

Татарстан Республикасы Рәисенең чит илләргә һәм Россия Федерациясе субъектларына визитларын әзерләү белән шөгыльләнәчәк төркемнәр юллау буенча тәкъдимнәр бирү;

Татарстан Республикасы җитәкчелеге катнашында чаралар уздырганда һәм чит ил партнерлары белән багланышларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның дәүләт беркетмәсе практикасы мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрү;

Татарстан Республикасы Рәисенең чит ил делегацияләре белән сөйләшүләрен һәм очрашуларын тәрҗемә итүне тәэмин итү; Татарстан Республикасы Рәисенең язышкан хатларын һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Рәисенең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең рәсми сайтында урнаштырыла торган материалларны тәрҗемә итү;

Татарстан Республикасы Рәисе визитлары һәм беркетмә очрашулары буенча белешмәләр базасын алып бару;

Россия Федерациясенең чит илләрдәге учреждениеләренең Идарә компетенциясенә кергән тәкъдимнәренә кагылышлы эшне оештыру;

даталар һәм вакыйгаларның еллык календарьләрен төзүдә катнашу;

чит илләр һәм Россия беркетмә практикасын өйрәнү һәм гомумиләштерү, Татарстан Республикасы беркетмә практикасын камилләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең башка бүлекчәләре белән берлектә Татарстан Республикасы Рәисе катнашындагы чараларны беркетмә-оештыру ягыннан тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын һәм башка документларны әзерләү.

Идарә Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләве буенча башка функцияләр башкара.

## IV. Идарәнең хокуклары

7. Идарә үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасына визитлар (иң югары һәм югары дәрәҗәдә) һәм Татарстан Республикасы Рәисенең чит илләргә һәм Россия Федерациясе

субъектларына визитларын әзерләгәндә федераль дәүләт органнары, Россия Федерациясенең чит илләрдәге учреждениеләре, Татарстан Республикасы вәкиллекләре, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарының тиешле структуралары белән хезмәттәшлек итәргә;

чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмалар җитәкчеләренең беркетмә хезмәтләре белән элемтәләрне дәвам иттерергә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фәнни һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## V. Идарәнең хезмәттәшлек итү даирәсе

8. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Идарә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

9. Идарә хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы.

## VII. Идарә эшчәнлеген оештыру

10. Идарәнең структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

11. Идарәгә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы

Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) җитәкчелек итә.

12. Идарә башлыгы:

Идарәнең эшчәнлеген оештыра, Идарәгә йөкләнгән бурычларның үтәлүе өчен җаваплы була;

Идарәнең төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенциясе чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Идарә хезмәткәрләре арасында хезмәт бурычларын бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарәнең структурасы, штат саны, Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм биләгән вазыйфасыннан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Идарә хезмәткәрләрен хезмәт командировкаларына җибәрү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән Идарә компетенциясенә кагылган мәсьәләләрне тикшергәндә катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Идарә вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнаширга җибәрә.

13. Идарә башлыгы вакытлыча эш урынында булмаган чорда, аның вазыйфаларын Идарә башлыгы урынбасары – оештыру-беркетмә бүлеге мөдире яисә Идарәнең башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

14. Идарә хезмәткәрләре Идарә башлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителә.

___________